КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 сентябрь г.Казань № 815

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 485 нче; 2018 ел, 24 август, 697 нче; 2019 ел, 19 апрель, 309 нчы; 2019 ел, 15 май, 394 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1177 нче; 2020 ел, 6 март, 179 нчы; 2020 ел, 21 сентябрь, 849 нчы; 2021 ел, 13 апрель, 244 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 956 нчы; 2022 ел, 25 март, 271 нче; 2022 ел, 29 июль, 731 нче; 2022 ел, 6 октябрь, 1075 нче; 2023 ел, 17 апрель, 481 нче; 2023 ел, 25 октябрь, 1351 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада татар текстында «Татарстан Республикасы оешмаларында эшләүче яшьләрнең» сүзләре үзгәрешсез кала;

1 пунктта «Артиас» иҗади хезмәткәрләр берләшмәсе» Казан шәһәр җәмәгать оешмасы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта:

икенче абзацта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта:

икенче абзацта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Фестиваль ел саен Татарстан Республикасындагы оешмаларда эшләгән, номинацияләр буенча фестивальдә катнашу һөнәри эшчәнлек төре булмаган яшьләр арасында уздырыла. Фестивальдә Татарстан Республикасындагы оешмаларның төп эш урыны буенча кимендә 9 айлык расланган хезмәт стажы булган 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп) хезмәткәрләре, шулай ук остазлар функциясен башкаручы һәм фестиваль чараларында команда составында катнашучы 36 яшьтән 50 яшькә кадәрге (50 яшьне кертеп) хезмәткәрләр катнашырга мөмкин.

2.1 пунктта:

икенче абзацта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы эшләүче яшьләренең глобаль социаль инициативаларына ярдәм күрсәтү;»;

2.2 пунктта:

икенче абзацта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «эшләүче яшьләр» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында оешмалар арасында иҗади элемтәләрне ныгыту, Татарстан Республикасы эшләүче яшьләренең һөнәри берләшүе процессына ярдәм күрсәтү;»;

3.2 пунктның җиденче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.5 пунктта «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте» сүзләрен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Команданың үткән фестивальләрдә аның өчен чыгыш ясаган һәм башка эш урынына яки элек чыгыш ясаган оешмада төп эш урыныннан тыш башка эш урынында эшләү статусына күчкән әгъзалары әлеге команда өчен генә чыгыш ясау шарты белән фестивальдә катнашуны дәвам итәргә мөмкин. Бу очракта яңа яки төп эш урыны буенча стажга карата таләп куелмый.»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Команда составында 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп) катнашучыларның гомуми саныннан Татарстан Республикасындагы оешмаларның остазлар функциясен башкаручы һәм фестиваль чараларында командалар составында катнашучы 36 яшьтән 40 яшькә кадәрге (40 яшьне кертеп) хезмәткәрләре – 50 проценттан, 41 яшьтән 45 яшькә кадәрге (45 яшьне кертеп) хезмәткәрләре – 25 проценттан, 46 яшьтән 50 яшькә кадәрге (50 яшьне кертеп) хезмәткәрләре 25 процenttан артмаска тиеш.»;

6.3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. Фестивальнең зона турларында җиңүчеләрнең барысы да дипломнар белән бүләкләнә.

Фестиваль финалында беренче, икенче һәм өченче урыннарны алган оешмаларның индивидуаль башкаручыларына, иҗади коллективларына һәм командаларына кубоклар һәм акча премияләрен раслый торган сертификатлар тапшырыла.

Фестиваль номинацияләре буенча барлыгы 92 акчалата премия һәм гомумкоманда зачеты йомгаклары буенча 15 акчалата премия түләнә, шул исәптән:

өч премия – һәрберсе 10,0 мең сум күләмендә;

биш премия – һәрберсе 10,5 мең сум күләмендә;

ун премия – һәрберсе 11,0 мең сум күләмендә;

сигез премия – һәрберсе 11,5 мең сум күләмендә;

өч премия – һәрберсе 12,0 мең сум күләмендә;

дүрт премия – һәрберсе 15,0 мең сум күләмендә;

биш премия – һәрберсе 16,0 мең сум күләмендә;

сигез премия – һәрберсе 17,0 мең сум күләмендә;

алты премия – һәрберсе 18,0 мең сум күләмендә;

тугыз премия – һәрберсе 18,5 мең сум күләмендә;

егерме премия – һәрберсе 19,5 мең сум күләмендә;

дүрт премия – һәрберсе 22,0 мең сум күләмендә;

җиде премия – һәрберсе 25,0 мең сум күләмендә;

дүрт премия – һәрберсе 51,0 мең сум күләмендә;

биш премия – һәрберсе 59,0 мең сум күләмендә;

алты премия – һәрберсе 65,0 мең сум күләмендә.

«Безнең заман герое» кубогы бирелгән командага диплом һәм 300,0 мең сум күләмендә акчалата премия бирүне раслый торган сертификат тапшырыла.»;

8.3 пунктта «Татарстан Республикасы Рәисе кубогы» сүзләреннән соң «, 500,0 мең сум күләмендә акчалата премия бирүне раслый торган сертификат,» сүзләрен өстәргә;

8.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

8.5 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган «Наше время – Безнең заман» эшләүче яшьләр иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы исемендә «эшләүче яшьләр» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, татар текстында «яшьләр» сүзен «яшьләре» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин